**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Олы Талкышы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Яр авылы торак пункты гражданнары җыены турында**

**КАРАР**

2018елның 24 ноябре №1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2018 елның 24 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Олы Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Яр авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, 2019 елда 100 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау ( вак таш сатып алу һәм китерү)

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукы булган җыенда катнашучылар исемлегенә 179гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 95 кеше катнашты.

Гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышлар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе буенча гражданнар җыенының 95катнашучысы тавыш бирде;

«Юк» позициясе буенча гражданнар җыенының 0 катнашучысы тавыш бирде.

.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Олы Талкыш авыл җирлегенең Кызыл Яр торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Олы Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Яр авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2019 елда 100 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау ( вак таш сатып алу һәм китерү) мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Чистай муниципаль районы Олы Талкышы авыл җирлегенең гражданнар җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларга һәм белдерү такталарына элү юлы белән халыкка белдерергә, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар  җыенында рәислек итүче
Олы Талкыш авыл
җирлеге башлыгы                                                  Э.Б.Ильин